**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**НОВОШЕШМИНСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯҢА ЧИШМӘ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2023 елның «06» июленнән № 155

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «2021-2025 елларга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү» муниципаль программасын раслау турында» 2020 елның 11 декабрендәге 323 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә физик культура һәм спорт турында» 2007 елның 4 декабрендәге 329-ФЗ номерлы Федераль закон, «Физик культура һәм спорт турында» 2008 елның 8 октябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «2021-2025 елларга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү» муниципаль максатчан программасын раслау турында» 2020 елның 11 декабрендәге 323 номерлы карары белән расланган «2021-2025 елларга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү» муниципаль максатчан программасына (2021 елның 08 июлендәге 281 номерлы; 2021 елның 23 августындагы 344 номерлы; 2022 елның 30 июнендәге 181номерлы карарлардагы үзгәрешләр белән) (алга таба - Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Программаның 6 бүлегенә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә: Күрсәтелгән учреждениеләрдә спорт төрләре буенча шөгыльләнүче спортчыларны әзерләү һәм йөртү буенча аутсорсинг хезмәтләре белән бәйле чыгымнары өлешендә муниципаль хезмәтләр күрсәтү, 2023 елга финанс

чыгымнары:

| | |
|---|---|
| Күрсәтелгән учреждениеләрдә спорт төрләре буенча шөгыльләнүче спортчыларны әзерләү һәм йөртү буенча аутсорсинг хезмәтләре белән бәйле чыгымнары өлешендә муниципаль хезмәтләр күрсәтү, финанс чыгымнары (республика бюджеты) | 140671,44 |
| Күрсәтелгән учреждениеләрдә спорт төрләре буенча шөгыльләнүче спортчыларны әзерләү һәм йөртү буенча аутсорсинг хезмәтләре белән бәйле чыгымнары өлешендә муниципаль хезмәтләр күрсәтү, финанс чыгымнары (җирле бюджет 1%) | 1406,71 |

2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «2021-2025 елларга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү» муниципаль максатчан программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 11 декабрендәге 323 номерлы карары белән расланган «2021-2025 елларга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү» муниципаль максатчан программасына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» 2021 елның 23 августындагы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат–телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда http//pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http//novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына (социаль мәсьәләләр буенча) йөкләргә.

Җитәкче Р. Р. Фасахов